Хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында

# ХӘБӘР ИТҮ

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1. Шәһәр төзелеше регламентлары;
2. Шәһәр төзелеше зоналаштыру картасы;
3. Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зона картасы;
4. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен куллану һәм күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибе.

Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:

1. Гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләнең асылы буенча чыгышлар.
2. Гавами тыңлауларда катнашучыларның сорауларын һәм тәкъдимнәрен карау.

Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга барлык чыгышлар тәмамланганнан соң сораулар бирергә хокуклы. Сораулар һәм тәкъдимнәр язма рәвештә бирелә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы: 2026 елның 17 февраленнән 2026 елның 24 февраленә кадәр.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе: Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты, җир кишәрлеге урнашкан территориаль зона чикләрендә даими яшәүче гражданнар, шушы территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, шундый җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыны һәм датасы:

-Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге;

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Мөрәле авылы, Үзәк ур., 45 й. адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитеты;

-Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Колаңгы поселогы, Бакча ур., 8 й.

Экспозициягә (экспозицияләргә) бару мөмкинлеге булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: 2026 елның 24 февралендә 8.00 сәгатьтән 11.40 сәгатькә кадәр.

Проектка кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше: проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2026 елның 17 февраленнән 2026 елның 23 февраленә кадәр 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, 2026 елның 24 февралендә 8.00 сәгатьтән 11.40 сәгатькә кадәр язма рәвештә кабул ителә:

-Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегендә;

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Мөрәле авылы, Үзәк ур., 45 й. адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитетында.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат 2026 елның 24 февралендә:

- 12.00 сәгаттә Кайбыч районы, Мөрәле авылы, Үзәк урам, 45 й. адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа карата мәгълүмати материаллар урнаштырылган рәсми сайт турында мәгълүмат: Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтының «Сайтка керүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлеге (http://kaybici.tatarstan.ru).

Әлеге хәбәрне Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында «Сайтка керүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм:

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й. адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк;

- Кайбыч районы, Мөрәле авылы, Үзәк урам, 45 й. адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы;

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Колаңгы поселогы, Бакча ур., 8 й. адресы буенча урнашкан йорт янындагы мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе

А.Н. Макаров